Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№1 (28) Октябрь-ноябрь, 2018 нче ел

## КОЛЛЕКТИВ ТУРЫНДА САНЛЫ АҢЛАТМА

| | |
|---|---|
| *«ТР физик тәрбия һәм спорт отличнигы» күкрәк билгесе* | *1* |
| *ТР ның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе* | *8* |
| *РФ Мәгариф һәм фән министрлы-гының Почет грамотасы* | *5* |
| *ТР Мәгариф һәм фән министрлы-гының Почет грамотасы* | *16* |
| *“Мәгариф” өстенлекле проекты җиңүчеләре* | *5* |
| *ТР 2010-2015 нче елларда мәгариф стратегиясен тормышка ашыручы “Иң яхшы укытучы” гранты иядәре* | *16* |
| *2016-2018 нче елларда ТР укытучылары-ның һөнәри үсеш гранты* | *10* |
| *Югары квалификацион категорияле укытучылар* | *16* |
| *Беренче квалификацион категорияле укытучылар* | *21* |

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Гимназия – тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы



Мөслим гимназиясендә туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучыларының чираттагы методик семинары үтте. Татар теле, әдәбият, тарих, биология фәннәре укытучылары белән берлектә, интеграль ачык дәресләр күрсәтелде. “Интеграль проектлар” мозаикасында укучылар фәнни эшләрен тәкъдим иттеләр. “Методик аукцион” оештырылды. Укытучылар дәреснең төрле этапларында ФГОС буенча куллана торган иң отышлы алымнарны видеороликлар рәвешендә тәкъдим иттеләр.

### Гимназия – экологик өйрәнүләр мәйданчыгы



Мөслим гимназиясе базасында региональ "Экокалейдоскоп" фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министрлыгы Ык буе территориаль идарәсенең өлкән белгече Э.Х.Вәлиева, Сарман, Актаныш, Минзәлә, Мөслим районы мәктәпләреннән укучылар катнашты. Дүрт укучы беренче урынны алдылар.

### Гимназия - сәләтле яшьләр территориясе



Мөслим гимназиясе базасында мәгариф идарәсе һәм Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты белән берлектә “Без – сәләтле буын” исемле фәнни-гамәли конференциясе үтте. Чарада 90 бала 4 юнәлештә көч сынаштылар. Җиңүчеләр Мактау грамоталары белән бүләкләнделәр.

Мөслим лицее базасында башлангыч сыйныфлар арасында “Бәхетле балачак” сәнгатьле сөйләм бәйгесе узды. Гимназия укучылары югары күрсәткечләргә ирештеләр.



### Гимназия - спорт территориясе

Район спартакиадасы кысаларында 20 нче октябрь көнне 5-9 нчы сыйныфлар арасында мини-футбол буенча ярышлар узды. И.Н.Сәетгалиев җитәкчелегендәге егетләр командасы беренче урынга лаек булды. Укытучы И.Н.Сәетгалиев “Иң яхшы тренер” буларак район мәгариф идарәсе грамотасы белән бүләкләнде.

## КОМСОМОЛГА - 100 ЯШЬ

***Тарихыбыз истәлекле вакыйгаларга бик бай. Быел 29 октябрьдә илебезнең киң җәмәгатьчелеге ВЛКСМ төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтте. Статистика буенча, илнең 200 миллионнан артык егет һәм кызы комсомол мәктәбен узган.***

***Ленин комсомолының данлы сәхифәләренә күз салсак, аның зур бер эпохага тиң булуын күрербез. Берничә буын совет яшьләрен берләштереп, аларны шәхес буларак, чын кешеләр итеп тәрбияләгән, иң авыр чакларда өлкәннәр белән иңгә-иң торып, ил язмышын хәл итүдә катнашкан комсомол бит ул.***

***Комсомоллар, кайда гына хезмәт куйсалар да, һәрвакыт алгы сызыкта, беренчеләр рәтендә булганнар. Комсомол оешмалары яшьләрне шәхес буларак тәрбияләп үстереп, аларга җәмгыятьтә үз урыннарын табарга булышкан.***

Шушы юбилей уңаеннан, үзебезнең укытучыларыбыз белән комсомол тормышы турында сораштырулар уздырдык. “Комсомол” сүзен ишетүгә, алар яшәреп киткәндәй булалар, еракта калган бәхетле яшьлек елларын искә төшерәләр.

**Ирина Владимировна:**

***Сезнең тормышыгызда комсомол нинди эз калдырды?***

Комсомол – алдынгы яшьләр оешмасы. 1984-1985 нче уку елында класста иң бернчеләрдән булып комсомол сафына кердем. Минем өчен бу бик зур дәрәҗә кебек иде. 2 ел Мөслим районы ВЛКСМ бюросы әгъзасы булдым. Бюро утырышлары бик эшлекле уза иде. Анда бик җитди мәсьәләләр карый идек. Мәсәлән, яшьләрнең ялын ничек уздырырга? Бу мәсьәләләрне тормышка ашыру да үзебезнең җаваплылыкта булды. Үз яшьтәшләребезне комсомол сафларына кабул итү аеруча истә калган. Миңа күпләр көнләшеп тә карый иде. Колхозларга чыгып, анда күчмә утырышлар ясый, авыл яшьләре өчен төрле чаралар оештыра, хәтта фермаларга барып, комсомолларның күпме сөт савуын тикшереп, контрольдә тота идек. Шул чакларны искә төшерәм дә, үзебездәге энтузиазмга шаккатам. Бүгенге яшьләрнең битарафлыгына борчылам.

**Зөлфирә Мухаровна:**

***“Не расстанусь с комсомолом, Буду вечно молодым” дигән шигарьне сез ничек кабул итәсез?***

Комсомолларның девизына әверелгән бу җыр яшәргә дәрт өсти, кушылып җырлыйсым, дөнья җимертеп эшлисем килә. Комсомол – минем яшәү рәвешем. 7 нче класста укыганда комсомолга кердем, класс комсоргы идем, шуннан 28 яшькә кадәр комсомол секретаре булдым. Минем тормышымның аерылгысыз бер өлеше ул – комсомол. Комсомол – тормыш мәктәбем.

***ВЛКСМ бетүне ничек кабул иттегез?***

Ул еллар авыр булып истә калган. Үземдә бер вакуум барлыкка килгәнен сиздем. Ярый әле укучылар булды. Комсомол рухын сүндермичә, оешма үзе булмаса да, хезмәтебезне шул рухта дәвам иттек.

***Сез комсомол билетыгызны саклыйсызмы?***

Әлбәттә, саклыйм. Ностальгия белән кулларыма алам, яшьлегемне искә төшерәм. Шул чорымның кадерле ядкәре бит ул.

**Маргарита Александровна:**

***Кем ул комсомол? Үзегезнең комсомолдагы эшчәнлегегез турында сөйләсәгез иде.***

Комсомол – маяк, яхшы үрнәк. Яшьлек дәрте белән янып, яшьнәп яшәүче, туган иленә тугрылыклы хезмәт итүче, үзен аямыйча эшләүче патриот. Комсомол тормышында бик актив булдым. Эшкә килгәч, Куйбышев колхозына пропагандист итеп куйдылар. Колхозчы яшьләр белән комсомол укулары уздыра идем. Әлбәттә, үзлектән күп укырга, өйрәнергә кирәк иде. Күбәк мәктәбендә эшләгәндә, Республика комсомолларының зона мәктәбендә укырга туры килде. Чувашиядәге комсомол оешмалары эшчәнлеге белән танышып, алар белән элемтәдә тордык.

Комсомоллар туплаган бай тәҗрибә, үрнәк буларак, һичшиксез, хәзерге һәм киләчәк буыннар хәтерендә сакланырга тиеш. Бу – хәзерге заман балалары һәм яшьләре өчен бик тә кирәкле, бик тә файдалы тәҗрибә. Исемнәре башкача яңгыраса да, гел беренче булырга, тормышны яхшы якка үзгәртергә, яңа максатларга омтылган комсомолны алмаштырырдай тәрбияви җәмәгать оешмалары җитми әле бездә. Заманалар ничек кенә үзгәрмәсен, ул чорларның комсомол-яшьләре башкарган данлы эшләр турында зур горурлык хисе белән балаларыбызга, оныкларыбызга сөйлик. Буыннар чылбыры өзелмәсен дип тырышыйк.

**Гөлшат Марсовна:**

***Комсомол булу Сезгә нәрсә бирде?***

Комсомол – бер горурлык хисе. Мәңге сүнми торган дәртле хис. Комсомол – йөрәктәге утлы күмер кисәге. Мәңге сүнмәс инде ул, күрәсең. Комсомол сафларында




тәрбияләнгән буын вәкиле буларак, мин бүген дә бөтен эшне җаваплылык тоеп башкарам, күңелем кушканча итеп эшлим.

***Комсомол тормышының иң күңелле бер мизгелен искә төшерә аласызмы?***

Хәзерге администрация бинасы коридорында ВЛКСМ Уставын яттан сөйләп, сорауларга җавап бирергә әзерләнеп, беркадәр каушап та, куркып та торганым кино кебек күз алдымнан үтте. 1989 нчы ел иде ул. Шулкадәр җаваплылык белән, бик дулкынланып әзерләндем. “Комсомол сафларына кабул ителүегез белән котлыйбыз” дигән сүзләрне ишетү үзе бер бәхет кебек иде. Шулай итеп комсомол тормышына кереп киттем. 1990 нчы елда комсомол активистларын Мәскәү шәһәренә экскурсиягә алып бардылар. Үзем кебек башка авыл комсомоллары белән аралашу, башкалабызга сәяхәт кылу нык матур сәхифәләр булып истә калды. Кызганыч, сәясәт үзгәрү нәтиҗәсендә, яшьләр оешмасы таркалды. Мин аны бик авыр кичердем. ВЛКСМ сафларында торган яшьлегем истәлеге итеп, комсомол билетымны саклыйм.

**Чулпан Алмазовна:**

***Комсомол сезнең тормышыгызда нинди роль уйнады?***

Комсомол - минем тормышымның фундаменты, нигез ташы. Комсомол тормышы – минем яшәешемнең аерылгысыз бер бик әһәмиятле өлеше ул.

Комсомол – ул романтика. Комсомол сафларында мин матур хыяллар, якты хисләр, киләчәккә өмет белән яшәргә өйрәндем.

Комсомол – зур тормыш мәктәбе. Комсомол мине коллективта эшләргә, яшәргә өйрәтте. Яшьлегемдә активлыкка, тырышлыкка, намуслы хезмәт белән яшәргә өйрәтүче

## КОМСОМОЛГА -100 ЯШЬ

тәҗрибә мәктәбе булды ул.

Комсомол – ул дисциплина. Комсомол тормышы тәртипкә күнектерде, камиллеккә омтылдырды, якты идеалларны маяк итеп яшәргә көч бирде.

Мин зур горурлык хисләре белән комсомол значогы тагып йөрдем. Кая гына барсам да, ул минем намусымның контролеры кебек булды.

Белем һәм тәрбия идеологиядә приоритет булып тора иде. Вакытлар үтү белән, кыйммәтләр үзгәрде. Көнбатыштан кергән цивилизация, идеология аркасында, без үзебезнең рухи дөньябызны үзебезгә ят нәрсәләр белән тутырдык. Бүгенге яшьләр, минемчә, информация ташкынында үз җаннарына кирәкле кыйммәтләрне сайлап ала алмыйча интегәләр, шуның аркасында рухи ачлык кичерәләр. Әдәби китап укып ләззәт алу тойгысы юк. Кемгәдер болай гына ярдәм итү, рәхмәт сүзен ишетеп рәхәтлек кичерү хисе таныш түгел. Бу кыйммәтләрне татырга безне комсомол өйрәтте.

**Ирина Тимерхановна:**

***Балачакта сез нинди оешмаларда тордыгыз? Хатирәләрегез белән бүлешегез әле.***

Октябрят, пионер, комсомол – болар минем балачагым, мәктәп елларым, яшьлегем кайтавазы. Комсомол сүзен мин исә гаиләдә, миннән олырак апа-абыйларымның: “Мине комсомолга алдылар”, - дигән сөенечле хәбәрләре аша ишеттем. Ә мәктәптә укый башлагач, Олег Кошевой, Зоя Космодемьянская, Александр Матросов кебек геройлар минем күңелемдә комсомолга карата аеруча зур кызыксыну, хөрмәт хисләре тудырдылар һәм комсомол сафларына керергә омтылу теләгенен тагын да ныгыттылар. Гомумән, без мәктәптә укыган елларда комсомолның чын-чынлап гөрләп эшләгән чорлары иде. Комсомолларның күркәм эшләре хакында радио, газет-журналлар аша укып, ишетеп тора идек. Үзебез дә әлеге оешмага тартыла идек.

Ни кызганыч, мина комсомол булу бәхете тәтемәде. Замана җилләре белән, бу оешма таркатылды. Минем комсомол булу теләгем шулхәтле көчле иде, хәзер дә бу тема - минем өчен авыр тема. Тормышка ашмый калган хыялым булып кына калды ул. Мин – гомерлек пионер. Пионер галстугын салыгыз, бәйләмәгез, дигәч, бала акылым аны кабул итә алмады. Ничек инде аны бәйләмисен?! Пионер булу – горурлык! Безнең бит үсеп комсомол буласы бар!? Пионер анты биргән буынның соңгысы булганбыздыр без.

**Лилиана Расиховна:**

Комсомол сүзе яшьлек, студент тормышы, группадашлар, турпоходлар, күмәкләшеп авыл хуҗалыгы эшләрендә йөрү, студент стройотрядлары тормышы, гитара белән җырлап утырулар белән ассоциацияләнә.

Шулай ук җаваплылык, киләчәккә якты хыяллар, матур тормыш төзү турында өмет, фидакарьлек, үзеңне аямыйча бөтен көчне куеп эшләү, алдынгы булырга тырышу... – болар ботенесе КОМСОМОЛ дигән төшен-чәгә сыйган.

Мин үземне бүген дә комсомол итеп хис итәм. Комсомолда алган тәрбия миңа башкача якка үзгәрергә ирек бирми. Гаделлек өчен көрәшү, һәр эштә алда барырга тырышу, җиренә җиткереп эшләү, принципиальлек – болар комсомол елларыннан калган байлыгым.



**Гөлнур Әзһәмовна:**

Комсомол үз сафларына иң алдынгы фикерле, белемгә, яңалыкка омтылучы талантлы, кыю йөрәкле, Ватаныбыз хакына гомерләрен дә аямаучы яшьләрне берләштергән. Комсомоллар һәрвакыт ялкынлы сүзләре, кыю эшчәнлеге һәм кабатланмас геройлык үрнәкләре белән тарих битләренә мәңгегә онытылмаслык булып кереп калды-лар.

Комсомол тормышы минем яшәү рәвешем, минем характерыма әверелде. Кайда гына чакырсалар да, кайчан кирәк булса да, үз кулымнан килгәнне намус белән башкарырга тырышып яшәдем. Район мәдәният йортында даими рәвештә үткәрелүче бәйрәмнәр, кичәләр, яшьләр арасында җыр, нәфис сүз бәйгеләре, комсомол туйлары, бәләкәй авыллар бәйрәмнәре үткәрү дисеңме, колхоз-совхоз басуларында, ындыр табак-ларында, җәйләүләрдә комсомол агитбригадалары белән ялкынлы чыгышлар оештыру дисеңме... боларның күбесе әле дә истә. Бер эштән дә йөз чөермәдек, үзебезнең төп эшебезне башкару белән бергә, ял көннәребездә кулга көрәк, сәнәк тотып, печән әзерләү, кышка ашел азык туплау, бәрәңге, чөгендер алу һ.б. эшләрдә дә бик теләп һәм ихластан катнаштык.

Кайда гына эшләсәм дә, минем янәшәмдә һәрчак булдыклы акыллы һәм сәләтле балалар, сәнгатьне яратучы яшьләр булды. Укытучылар коллективында да бер-беребезгә тая-нып, аңлашып эшләдек. Шуңа күрә дә безнең һәр эшебезнең нәтиҗәсе уңышлы, сөенечле була иде. Без беркачайн да данга, акчага кызык-мадык. Дөресен әйткәндә, акча бармы, юкмы – без ул турыда уйламадык та. Күпме бар шуңы яши идек, һәм ул бөтен нәрсәгә дә җитә иде. Артык кием-салым җыймадык, үзебезгә охшаган, заманча ятышлы киемнәрне үзебез тегеп кигән чаклар да булды. Һәрнәрсәдә тыйнак булдык.

Бүгенге көндә дә шул “комсо-моллыгым”ны куам. Коллективымның бер патриоты инде мин. Хезмәтемне яратып башкарам, яңалыкка омтылып, бирелеп эшлим. Сабый балаларга белем-тәрбия бирү аша Ватаныма хезмәт итәм, халкымның матур киләчәгенә үз өлешемне кертергә тырышам.

**Нәкыя Мирзануровна:**

***Комсомол тормышы сезгә нәрсә бирде?***

Ул елларны мин бик сагынам һәм аерым бер җылылык белән искә алам. Һәм мин ул чорда яшәгән бездән өлкәнрәкләргә бик тә рәхмәтлемен, чөнки алар, зирәклек күрсәтеп, безгә яшьлек идеалларыбызны тормышка ашырырга юл куйганнар. Мин яшьтәшләремә дә шулай ук бик рәхмәтле, чөнки алар безгә чын мәгънәсендә ышанганнар, безгә ияргәннәр, безнең эшчәнлегебезне куәтләп торганнар!

Комсомолда хезмәт иткән елларым минем өчен зур тормыш мәктәбе булды, нәкъ шул чорда мин зур хезмәт чыныгуы алдым, кешеләр белән аралашу, зур эшләр оештыру сәнгатенә өйрәндем, үзем үземне ачтым, зур коллективта хезмәт оештыру серләренә төшендем. Гомумән, мин гомеремнең бу чорына, Комсомолга чын мәгънәсендә рәхмәтлемен!

Бу минем өчен зур катлаулы тормышка юл башы иде! ...һәм иң кыйммәтлесе шунда – комсомол эшчәнлеге миңа тормышта һәрдаим кирәкле рухи ныклык тәрбияләде!

***Укытучылардан интервьюны 11 нче а сыйныфы укучысы Сабитова Айгөл алды.***

## ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР МӘЙДАНЫ

### ӘНИЕМ

Гөл-чәчәкләрдән дә матур,
Кояштан да яктырак.
Акыллы, йомшак, сөйкемле –
Кем бар аннан назлырак?

Русчалап әйтәм мин аңа:
“Я тебя люблю”, - диеп.
Инглизчәләп әйтә алам:
“Әни, I love you”, - диеп.

Чын йөрәктән үз телемдә:
“Әнкәем-бәгърем,” – дисәм,
Кочаклап сөя ул мине,
Мин исә “эреп бетәм”.

### ЯРДӘМ ИТИК КОШЛАРГА

Кечкенә дусларыбызга
Игътибарлы булыгыз.
Кошлар – безнең дусларыбыз
Җимлек ясап куегыз!

### КИТАП

Әле ярый бала чакта
Әйбәтләп уйнап калдым.
Хәзер уйнарга вакыт юк –
Кулыма китап алдым.

Әбием гел әйтеп тора:
“Иң яхшы дус ул – китап”
Дуслык бик тиз бозыла ул
Дус түгел белән бутап.

Китап – белем чишмәсе ул
Аңлый белгән кешегә.
Ләкин аны аз укыйлар –
Интернет бар һәркемдә.

***Камилла Шамсиева,***
***6 нчы а сыйныфы укучысы***



### РӘХМӘТЛЕМЕН

Рәхмәтлемен кояш чыгып,
Якты көннәр туганга,
Кояш баеп төн булганга,
Йолдызлар кабынганга.

Рәхмәтем әти-әнигә,
Дуслар, укытучыларга.
Рәхмәтлемен барчагызга –
Бәхетле сез булганга.

***Алия Ихсанова,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

### ӘНИЕМӘ РӘХМӘТЕМ

Рәхмәтлемен Аллахемә
Җирдә яшәгән өчен.
Рәхмәтле мин кояшка
Җылы нурлары өчен!

Рәхмәтле мин чишмәләргә,
Чиста сулары өчен.
Рәхмәтле мин болыннарга,
Чәчәкләргә, кошларга.
Бу дөньяга туган өчен,
Рәхмәтле әниемә.

***Зөһрә Закирова,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

### ӘНИЛӘР - ТОРМЫШ ЯМЕ

Ягымлы сүзегез
Бик матур үзегез.
Кояштай нурлана,
Елмая йөзегез.

Тормышның сез яме
Гомернең сез тәме.
Тик сездә, әниләр,
Яшәүнең дәвамы.

***Илһам Бариев,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

### УРАЗА АЕ

Ураза ае җиткәнен
Һәр елны көтеп алам.
Намазларны калдырмыйча
Барын да укып барам.

Әби-бабам – өчәүләшеп
Сәхәр ашыйбыз бергә.
Бик тиз үтә озын көннәр
Авыр түгел ул бер дә.

Уразасыз аңлап булмас
Иртәнге чәй тәмнәрен.
Сәхәрдән соң йокыларның
Ничек тәмле икәнен

Кояш баткач авыз ачам,
Намаз укыйбыз бергә.
Ураза ае – Рамазан
Зур бәйрәм хәзер безгә.

***Әдилә Бәдертдинова,***
***6 нчы а сыйныфы укучысы***

### БАЛАЛЫК РӘХМӘТЕМ

Саклап торсын, яклап торсын
Әнием, теләкләрең.
Гомерләреңә җитәрлек,
Балалык рәхмәтләрем.

***Илнар Исламов,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Октябрь-ноябрь, 2018 нче ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Галимова Алсу
**Корректорлар:** Сабитова Айгөл, Әхмәтҗанов Булат
**Корреспондентлар:** Бадретдинова Әдилә, Идиятуллина Сабинә
**Дизайнер:** Шәкертҗанов Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Таһир, Хафизова Ильгина
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж**: 100